ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРМАШ_БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРМАШ_БАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.10.2019** Сармаш-Баш авылы **№ 10**

**«Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урынын раслау турында» 2014 елның 07 апрелендәге 09 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгы карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының үзгәрешләре нигезендә, "Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян салынуга китерергә мөмкин җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, алар белән эш итүнең кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 03 сентябрендәге 681 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. «Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урынын раслау турында» 2014 елның 07 апрелендәге 09 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Сармаш-Башлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы** **Р.М.Фәсхетдинов**